| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ТАШКИЧИНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ул.Г.Тукая, д. 19, с.Ашитбаш,<br>Арский муниципальный район, 422039 | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ТАШКИЧҮ<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ<br>Г.Тукай урамы, 19 йорт, Ашытбаш авылы,<br>Арча муниципаль районы, 422039 |

Тел. (84366)90-2-58, факс (84366)90-3-22. E-mail: Tash.Ars@tatar.ru

# КАРАР

“05” июль 2019 ел №2

Җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында

Россия Федерациясенең 2003 елның 6 октябрендә чыккан «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 2131-ФЗ номерлы законы, “Ташкичү авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы һәм хокукый актлар проектлары турында фикер алышуда катнашуда “Ташкичү авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге халкының хокукларын тәэмин итү максатында 2018 нче елның 22 нче октябрендә чыгарылган 14 номерлы Совет карары белән расланган “Ташкичү авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә ачык тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмә”гә яраштырып, карар бирәм:

1. “Ташкичү авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында карар проекты буенча җәмәгать тыңлауларын” 2019 елның 5 августына билгеләргә.

2. “Ташкичү авыл җирлеге” муниципаль берәмлегендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында карар проекты буенча ачык тыңлаулар”ны Арча муниципаль районы, Ашытбаш авылы, Г.Тукай урамы, 19 нчы йорт адресы буенча 2019 елның 5 августында 10:00 сәгатьтә үткәрергә.

3. Гражданнарның “Ташкичү авыл җирлеге” муниципаль берәмлеген төзекләндерү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәрен һәм җәмәгать тыңлауларында катнашу турында язмача гаризаларын 5 августның 16:00 сәгатенә кадәр Арча муниципаль районы, Ашытбаш авылы, Г.Тукай урамы, 19 нчы йорт адресы буенча җибәрергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында бастырып чыгарырга (http:pravo.tatarstan.ru), Арча муниципаль районының рәсми сайтында (arsk.tatarstan.ru) һәм Ашытбаш авылы, Г. Тукай урамы, 19 нчы йорт; Ташкичу авылы, Ленин урамы, 53 нче йорт; Иске Ашыт авылы, Мәктәп урамы, 4 нче йорт адреслары буенча мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Җирлек башлыгы Фәйзуллин Ф.Х.